Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы башкарма комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИE** **КАРАР**
**25.12.2018 г.** **№29**

**Җәлил шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге территориясендә фейерверк һәм салютлар җибәрү өчен урыннар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә «Пиротехника әйберләрен таратканда һәм кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен раслау турында " 2009 елның 22 декабрендәге 1052 номерлы федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы белән Яңа Ел бәйрәм чаралары чорында гражданнарның һәм объектларның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Карар бирәм:

1. Сарман районы, Җәлил ш. т. п., Әхмәдиев ур., 30а йорт адресы буенча «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә фейерверк һәм салютлар җибәрү урыны итеп билгеләргә;
2. Фейерверк урнаштырганда мәйданчыкны саклау һәм гражданнарның иминлеге фейерверк уздыра торган оешмага яки затка йөкләнә. Тамашачылар җил искән якта булырга тиеш.
3. Фейерверк үткәрү урыныннан бина һәм тамашачылар өчен куркынычсыз ераклык кулланыла торган пиротехника әйберләре инструкциясе таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә, шулай ук мәгълүмати стендларда урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Башкарма комитет җитәкчесе И.Ф. Галлямов